

Авылым чишмәләре
Суның башы тауда,
аягы-диңгездә.

Һәр чишмәнең туган җире була,
Туган җыры була үзенчә,
Аккан юллары һәм язмышлары,
Кешеләрнекечә, безнеңчә.
Чишмәләргә төшкән сукмакларда,
Сагынып елый кебек үткәнен,
Яратмыйдыр ул да эзләр бетеп
Өсләренә чирәм үскәнен.

# Изге Шәех бабай чишмәсе.




Бертуктаусыз көн-төн ага,
Бөтен кеше рәхмәт әйтә аңа.

Бүгенге көндә чиста су проблемасы үзен сиздерә. Тәбигатебезнең пычрануы нәтиҗәсендә күп кенә елга, сулыклар, чишмәләр корый, юкка чыга. Шуңа күрә дә безгә булган чишмәләрне сакларга кирәк.

# Озын улак чишмәсе



# Авылым чишмәләре.


Авылымның челтер-челтер аккан сихерле чишмәсе ул берәү анысыда булса –Шәех баба чишмәсе. Аның суы чиста һәм тәмле. Шуңа да карамастан күзләргә шифа бирә һәм эчсәң суын әллә нинди бер җан биреп дәвалый. Аның суын чиләк-көянтә белән ташыйлар. Шифасы бик дәва. Авылдашлар бик яратып эчәләр.

Безнең авылда “Шәех баба” чишмәсе генә түгел бит эле, алар бишәү: “Озын улак” чишмәсе, “Матур чишмә”, “Кирәмәт” чишмәсе, “Габит” чишмәсе. Һәр чишмәнең үз шифасы һәм үз матурлыгы бар. Без “Озын улак” чишмәсеннән көн дә чиләк-көянтә белән су алып кайтабыз. Аның суы йомшак,тәмле һәм шифалы. Чишмәләребез караулы, аларны гел чистартып торалар. Ә “Габит” чишмәсенең суын эчсәң тәннәрең сихәтләнеп, авыруларың басылып киткән кебек була. Бу чишмәне авылыбызның Габит исемле кешесе карап чистартып торган, аның исеме белән хәзер чишмәбез аталып йөртелә.

Минем шуны әйтәсем килә, булган чишмәләрне саклап, чистартып торырга кирәк. Табигать биргән байлыкны саклау безнең изге бурычыбыз – ул.

# “Матур” чишмәсе

Тау астында анасы, чыгып кача баласы.




Тауда туса
да тауны
яратмый.


Чишмә буйларында туып үстем
Үз авылым шунда, үз йортым.
Тынар иде җаным, эчсәм әгәр
Чишмәбезнең суын бер йотым.